**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 11 май № 296

г. Казань

«Буа ветеринария техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турында

Татарстан Республикасында һөнәри мәгариф системасын үзгәртеп кору һәм эш бирүчеләрне һөнәри белем бирү оешмалары белән идарә итүгә җәлеп итү буенча чараларны тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Буа ветеринария техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының гамәлдәге «Буа ветеринария техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенең төрен үзгәртү юлы белән, аның эшчәнлегенең төп максатларын саклап, «Буа ветеринария техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба –техникум) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Техникумның гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

60 көн эчендә «Буа ветеринария техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе Уставына (алга таба – Устав) тиешле үзгәрешләр кертергә һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә аларны дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

Уставка кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 көн эчендә техникумның күзәтүчеләр советын расларга;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына элек «Буа ветеринария техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенә беркетелгән, техникум эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булган дәүләт мөлкәте исемлеген, шулай ук беркетелә торган күчемсез милек объектларына техник документацияне тапшырырга;

ел саен техникум өчен аның Уставында каралган төп эшчәнлеге нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен расларга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә Уставка кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң:

30 көн эчендә техникумга оператив идарә итү хокукында элек оператив идарә итү хокукында « Буа ветеринария техникумы » дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән аеручы кыйммәтле күчемле милекне беркетергә;

120 көн эчендә әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә техникумга беркетелә торган күчемле милек объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) куллану хокукында бирүне тәэмин итәргә.

5. Техникум тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә тиешле тәртиптә Уставка кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларын торак урыннар белән тәэмин итүгә нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 16 октябрь, 776 нчы карарына аны бу карарның 1 нче пунктына яраклаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» карар проектын әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Татарстан Республикасы Финас министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының җыелма бюджет язуына тиешле үзгәрешләрне керетргә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерү тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков